СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**23 октябрь, 2024 ел** **№ 464**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесен билгеләп кую турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34, 37, 85 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларны карап, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе вазыйфасына 2024 елның 24 октябреннән Хәкимуллин Рамил Фатих улын билгеләп куярга.
2. Биектау муниципаль районы Башлыгына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе белән Контракт төзергә.
3. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе вазыйфаларын 2024 елның 23 октябреннән башкаруны йөкләү турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 442 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Биектау хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов